# Рухи сәламәтлек һәм информация

Галимә ХАРИСОВА

Пәйгамбәребез әйтеп калдырган: “Өммәтемнең иң явызлары шул кешеләрдер ки, байлык һәм ниъмәт эчендә туарлар, яхшы ашап-эчәрләр, матур-матур киемнәр киярләр, яхшы атларга менәрләр, әмма яхшы сүз сөйли белмичә, гомерләрен уен-көлке кичерерләр”.

“Информация” - латин сүзе, “кешеләргә тел, язу һәм техник чаралар аша мәгълүматны ирештерү” дигән мәгънәләргә ия.

Пәйгамбәребез: “һәрбер бала фитри иманда туа, ләкин ата-анасы аны яһүдигә, яисә насарага, яки мәҗүсигә әйләндерә”, - ди. Мөселман гаиләсе иң элек иманлы булуы белән аерылып тора һәм баласының фитри иманын сакларга һәм куәтләргә бөтен көчен сарыф итә, баласы башка дингә кермәсен, яисә динсезлек сазлыгына батмасын өчен кисәтү чараларын куллана.

Әйе, баланың фитри иманын дини тәрбия һәм дини тәгълим белән генә саклап калырга һәм куәтләргә була. Кешенең эчке дөньясын бер савыт кебек күз алдына китерергә була. Савытка нәрсә генә салсак та, аның эчендә бер куник, катлам кала. Ул катлам пычрак булса, анда төрле гөмбәчекләр, микроблар җыела, савыт тәмам пычрана. Шулай ук кешегә ирешкән һәр сүз аның күңеленә тәэсир итә.

Кешенең калебе иман белән тулса гына ул сәламәт була. Динебез һәрчак тән ихтыяҗларына тиешлесен биреп, кешенең инстинктларын җайга салып, тиешле рухилыкны, әхлакыйлыкны беренче урынга куя.

Совет чорында кешенең калебе ялган атеистик идеология белән агуланды, хәләл, хәрәм төшенчәләре юкка чыкты, бу агулау хәзер дә дәвам итә. Нәтиҗәдә, әхлаксыз, миһербансыз 4 буын тәрбияләнде. Табиблар, хастаханәләр артса да, фән-техника алга китсә дә, авырулар саны кимеми. Халык алкоголизм, наркомания, СПИД кебек социаль авырулардан һәлак була.

Тән ихтыяҗларына өстенлек бирү, байлык артыннан куу, барлык хакыйкый рухи мөнфәгатьләрне киметү, аннан бөтенләй баш тарту халыкны имансыз калдырды. Хәзерге чорда әхлаксызлык чәчәк ата. “Әүвәл, әхлак бозылса, икенчедән, дин бетә, өченчедән, ул халык үзе бетә”, - ди Гаяз Исхакый. Бетүгә таба барабыз. Россиягә һәм башка, хәттә икътисади яктан алга киткән илләргә дә демографик кризис яный.

Әлхәмдүлилләһ, Аллаһының рәхмәте белән инде ике дистә елга якын дин тоту иреге бирелде. Акыл ияләре күңелләрендәге шакшы информацияне тәүбә-истигъфарлар белән пакьләп, Коръән, Сөннәт гыйлемен үзләштереп, калебләрен Аллаһы Тәгаләгә мәхәббәт, Аннан гына курку, Аңа гына өмет багълау, тәвәккәл кылу хисләре белән тутыралар, намаз укыйлар, уразалар тоталар. Ләкин Аллаһка юнәлгән бу туры юлда адәми һәм җеннәрдән булган шайтаннар утыралар, мөэмин-мөселманнарны бу юлдан тайпылдыру өчен бөтен көчләрен сарфы итәләр.

Газета һәм журналлардагы мәкаләләр, радио-телевидение аша көне-төне алып барылган тапшырулар, бу дистәләрчә каналлардан ирештерелгән информация ташкыны кешеләрне тулысынча ахирәттән баш тартырга, бу дөньяга гына игътибар итәргә, динне мәсхәрәләргә, дәһрилеккә, көчләүгә, талауга, җенси азгынлыкка нигезләнгән мәдәният өчен горурланырга чакыралар.

Кешелек тарихының һәр заманында күпчелекне үз ихтыярларына буйсындырырга теләүче, үзләрен илаһ дип игълан итүче фиргавеннәр, гитлер, сталиннар булган. Алар үзләренең максатларына кешеләрне җәзалап, көчләп, үтереп, кан коеп ирешә торган булганнар. Хәзер бу ысуллар законнан тыш.

Ләкин алар үзләренең максатларыннан бер адымга да чигенергә теләмиләр, тик ысулларын гына үзгәрттеләр. Телекоммуникация, компьютер технологияләре һәм киң мәгълүмат чаралары миллионлаган кешеләрне үз ихтыярларына буйсындырыр өчен бу власть сөючеләргә чиксез мөмкинлекләр бирделәр. Кешеләрне физик юк итүдән алар рухи көчләүгә күчтеләр, рухи тәэсир аша алар кешеләрнең тәртибен программалаштыралар.

Магнитофон, радио, телевизор, интернет, мобиль телефоннар аша бу технологияләр һәр өйгә килеп керде, һәр кешегә иреште. Телеэкраннардагы хайвани ерткычлык, көчләү, төрле аномаль сексуаль мөнәсәбәтләргә алып баручы порнографиянең күп төрләре, бозыклык, оятсызлык, үтереш-көчләү ташкыны үргып, җәмгыять өстенә килә, кешенең акылы, ихтыяр көче зәгыйфьләнә, түбән хисләре, инстинктлары өскә калка.

Мондый нечкә һәм камилләшкән тәҗрибәләр нәкъ безнең өстә эшләнә. Берничә ел эчендә фикерләү тибы үзгәрә, рухи кыйммәтләр һәм әхлак кануннары аяктан башка әйләндерелә, начарлык яхшылык итеп күрсәтелә. Бу технологияләр ярдәмендә кешеләрнең фикерләрен үзләренең халкына, иленә, тарихына, мәдәниятенә, хәтта Аллаһы Тәгаләгә каршы борып җибәрәләр. Дәһри идеологияләрнең җимергеч тәэсире аркасында күп буыннар һәм меңләгән кешеләр исламнан читләштеләр һәм Аллаһыдан башка табыну объектлары табып, мөртәт булдылар.

Хайвани инстинктларны кузгатучы рухи наркотикка кеше бик тиз ияләшә. “Зәңгәр тартма” фатирларда кешенең аерылгысыз бер потына әверелде. Әлеге тартмадан кеше рухи азык эзли, олысы, кечесе айлар буе сузылган киносериаллар карый, һәр серияне сагынып көтеп ала, киногеройларга ияреп үзе дә хыялый тормышта яши башлый, алар белән бергә кайгыра, шатлана. Әлеге кино сөючеләрнең фикерләү сәләте кими, мондый мавыгу тора бара симерү, инфаркт, тромбоз, мидәге яман шеш, катаракта, шикәр авыруларына да китерә.

Телевизорны кеше белән идарә итүче машина диләр. Кешенең әзлексез телевизор каравында һәм азартлы уеннар, наркотиклар белән мавыгуда уртаклык барын күрәсең. “Азарт” - француз сүзе, “үз-үзеңне куркыныч астына кую, мавыгу” дигәнне аңлата. Наркоман кебек телевизорга бәйләнгән кеше дә сихри тартмадан аерыла алмый, һәр буш минутын шуңа багышлый. Эчкече рюмкага үрелгән кебек,аның кулы автоматик рәвештә телевизор пультына үрелә.

Хәзерге заманда үзен мөселман дип санаучылар да бу телевизор дигән шайтан тозагына бик тиз эләгәләр. “Мин Аллаһыга ышанам, ләкин намаз укырга вакытым юк”, диючеләр бик күп. Шул ук кешеләр сәгатьләр, еллар буе хәрәм булган телесериаллар карап утыралар, зәгыйфь иманнарыннан да колак кагалар. Олысы, кечесе, әбиләре, бабайлары бөтен дөньяларын онытып, чын күңелдән бирелеп, шулар өчен кайгырып, бандитлар, зина кылучылар турындагы киноларны карыйлар. Өйләрендә намаз вакытларын күрмәссең, ә телепрограммалар һәрвакыт кул астында.

Бервакыт ерак бер районнан бер ханым миңа гомеопатик приемга килгән иде. Даруларны биргәч, Аллаһтан намазлар укып шифа сора дидем. Ул: “Аллаһка ышануын ышанам, ләкин намаз догаларын истә калдыра алмыйм”, - диде. “Телевизор карыйсыңмы соң?” - дигәч, “Карамаган кая, “Богатые тоже плачут” дигән сериалдагы Роза язмышына кайгырып, инфаркт дигән авыруга дучар булдым да инде”, - диде.

Менә шулай итеп, кеше телевизор аркасында реаль тормыштан аерыла, үзен дә, Аллаһы Тәгаләне дә оныта.

Кайберәүләр, мин татарча сериалларны гына карыйм, дип аклана. Алар да шул Америка төшергән урлашучылар һәм зиначылар турында. Бу киноларның исемнәре генә дә куркыныч: “Адашкан мәхәббәт”. Шуларны караганда кеше үлеп китсә, Аллаһ каршында бу соңгы гамәле өчен ничек җавап бирер?

Җәмгыятебездә күпчелек кешеләрнең рухи эшчәнлеге, уй-фикерләре, әхлакый нормалары фәнни һәм әдәби әсәрләр рәвешендә күзаллана. Галим, шагыйрь, композиторлар, рәссам һәм скульпторлар башларында туган идеяләр һәм образлар аша кешеләр рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерәләр.

Әдәби әсәр кешенең иманын куәтләргә тиеш, ә кайбер татар “классикалары” – (“классик” - үрнәк булырга лаек дигәнне аңлата) Көнбатыш язучыларыннан да уздыралар, мәхәббәт, ягъни зина хакында гына язып калмыйлар, Аллаһыдан, Аның Рәсүленнән, Аның фәрештәләреннән көлә торган әсәрләр язалар, режиссерлар аларны сәхнәләштерәләр. Кайберәүләрнең җаһиллекләре шулчаклы көчле, шул шамакайларны акча түләп, көлә-көлә үзен мөселман дип санаган татарлар карап утыра.

Ә бит кем Аллаһының диненнән көлсә - кяфер булды, кем бу көлкедән риза булса, шул ук хөкемдә каралырга мөмкин. Сак булыйк, иң кадерле байлыгыбыздан - иманыбыздан мәхрүм калмыйк.

Кешенең калебенә сүздән дә артыграк җыр тәэсир итә. Бүгенге көндә татар халкы җыр-моңга бигрәк тә бирелеп китте. Күп артистларны тамашачы үзләренең илаһлары итеп алды. Алар кебек киенәләр, концертларына йөзләрчә акчалар түләп баралар, шуларны тыңлап ләззәтләнәләр. Ә җырчылар, театр артистлары үзләренең гамәлләре белән яхшылык эшлибез диләр. “Җыр ул - юаныч, тормышта таяныч, көч-куәт, илһам чыганагы”, - дигән ширки, Аллаһка тиңдәш кылу сүзләре сөйлиләр. Мөселманның юанычы да, таянычы да Аллаһ, Аннан башка бер көч, куәт тә юк. Кайбер артистлар без мөселман, намаз укыйбыз диләр, ә үзләре кешене намаздан аздыралар, концертлары намаз вакытында, үзләре хәрәм булган җырлар җырлыйлар, хәрәм булган музыкаль инструментларда уйныйлар, ярымчишенгән хатын-кызлар килешсез киемнәре, талпыну хәрәкәтләре белән тамашачыны зинага этәрәләр.

Димәк, алар, дин күзлегеннән карасак, яхшылык түгел, яманлык эшлиләр. Мондыйлар хакында Аллаһы Тәгалә Коръәндә: “Сезгә бәян кылып, төшендереп биримме үзләренең гамәлләре белән хәсрәттә, югалтуда булучыларны, үзләренең гамәлләре белән һичбер нинди савапка ирешми торган кешеләрне. Алар шундыйлар, үзләре яхшылык эшлибез дип уйлыйлар, ә үзләре Раббыларының аятьләренә һәм кубарылып Аллаһыга юлыгуга ышанмыйлар, аларның барча гамәлләре юкка чыкты. Кыямәт көнендә аларга изге дип санаган эшләре өчен үлчәү дә куймабыз, чөнки үлчәргә саваплары булмас. Бу җәһәннәм аларга тиешле булды кяфер булганнары өчен вә рәсүлләребезне мәсхәрә кылганнары өчен.”

Динебездә көчләү юк, ләкин өндәү бар. Кояш мәгърибтән чыкканчы, үлем агониясенә ирешкәнче, һәркемгә тәүбә ишекләре ачык. Хакыйкый рухи кыйммәтләрне суррогатлардан аеру өчен, Аллаһы Тәгалә безгә акыл нигъмәте һәм сизгер күңел биргән.

Урта һәм өлкән яшьтәгеләр җыырга-моңга гашыйк булса, яшьләр исә рок музыкадан башка яши алмыйлар. рок-поп музыка көне-төне радиотелевидениедән дә яңгырый, күпләр, аны урамда да, транспортта да тыңлый. Пәйгамбәребез музыкаль инструментларда уйнауны, тыңлауны хәрәм икәнен 14 гасыр әүвәл хәбәр иткән. Ләкин кешеләр моңа колак салмыйлар, бу музыканы тыңлап, үз-үзләрен әкренләп үтерәләр. Галимнәр яңа гасыр авыруы - “ритмичный токсикоз” турында язалар. Бу авыру белән интегүчеләрдә бик нык баш авыртуы, йокысызлык, косу, организмның тулысынча арыклануы күзәтелә. Фәнни тикшерүләр билгеле бер ритмда һәм тембрда булган тавышлар кешенең иммун системасын какшатуын раслады.

Әйе, динебездә бер генә дә тыю хикмәтсез түгел, кешенең сәламәтлеген саклауга юнәлтелгән. Динебез - яшәү рәвеше. Мөэмин-мөселман төрле хәрәмнәрдән ваз кичә. Үзенең нәфес теләкләренә хуҗа була.

Бүгенге көнгә тагын бер хас сыйфат ул - өлкәннәр “уенчыгы” - мобильный телефоннар. Кәрәзле телефоннар бүгенге заман таләбе, алар бүгенге тормышыбызда аеруча зур урын били башлады. Ләкин бу уңай әлемтә чарасының михнәте дә бар икән.

Галимнәр раславынча, кәрәзле телефон белән кулланучы кешеләрдә психик үзгәреш, артык борчылу, ярсу кебек нормадан тайпылышлар күзәтелә.

Кәрәзле телефон белән файдаланучы кешенең тәне антенна элементы булып файдаланыла, телефонны колакка якын китерү белән баш миенең биоэлектрик активлыгы 30 секунд үтүгә үк үзгәрә. Һәҗүмгә дучар ителгән баш мие ашыгыч рәвештә саклану чарасын күрә башлый һәм организм шуңа бәйле үтә катлаулы процесслар белән үзен якларга тырыша. Ләкин кеше нурланыш алу хакында уйлап та карамый. Чит илләрдә тәмәке пачкасына язган кебек, мобильный телефонның тышына да: “Сак булыгыз! Сәламәтлек өчен зыянлы” дип язып куялар, диләр. Кесә телефоннарына бәйлелек формалашуы хакында да галимнәр торган саен ныграк хәвефләнә башлады. Ничек кенә булмасын, кәрәзле телефонның безнең организмга куркыныч тәэсирен без аңларга тиеш һәм чамадан тыш куллануга юл куймаска тиешбез.

Телевидение, компьютер, интернет - кешелекнең бәяләп бетергесез табышы. Һәрбер фәнни ачыш, инновацион технологияләр Аллаһы Тәгаләнең теләге, рөхсәте белән генә барлыкка киләләр. Аларны рухи дөньяңны җимерү яисә иманыңны куәтләү өчен дә кулланып була. Үзебезне, гаиләбезне, милләтебезне, мәгълүмат чараларының һәлакәткә илтүче тәэсиреннән коткару өчен, җыен шакшы информациягә Аллаһы Тәгаләнең хак сүзен - Коръәни-Кәримне каршы куярга тиешбез. Бу информацион сугышта Аллаһының сүзе, Пәйгамбәрләребезнең юлы - безнең коралыбыз һәм калканыбыз.

Аллаһы Тәгалә: “хаклы - Коръән килде, батыйл - ялган китте, чөнки хаклык янында батыйл бетә торган булды”, - ди.

Коръәни-Кәрим иңгәнгә 14 гасыр вакыт үтеп китте, ләкин хаклык урынына ялган тарала, куәтләнә, чөнки аңа каршылык чаралары күрсәтелми. Дөнья һәм ахирәт өчен файдалы булган сүзләрне, ислам диненең нигезләрен таратуда без вакытыбызны, көчебезне, малыбызны да кызганмаска тиешбез. Әгәр хаклыкка өндәмәсәк, Аллаһы Тәгалә риза булмас, догаларыбыз да кабул булмас.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә, ислам дине өстен чыгачак диде, шуңа күрә без өметсез булмаска тиешбез. Бу һичшиксез тормышка ашачак процесста без читтә калсак, безгә әманәт итеп бирелгән Коръәни-Кәримне балаларыбызга, киләчәк буынга, тирә-юндәге кешеләргә тапшырмасак, әҗер вә савапсыз калачакбыз.

Динсез дәүләтләрдә әхлак кагыйдәләре ирекле рәвештә, мәгълүмат чаралары аша формалаша, төрле ямьсез күренешләр бик тиз генә рәсмиләшеп китә һәм беркемне дә гаҗәпләндерми башлый. Бер төркем халык гөнаһ эшләргә бик тиз гадәтләнеп китсә, икенче яктан бик күпләр мондый анархиягә әверелеп киткән демократиядән туеп, хак юлны эзлиләр һәм, нәтиҗәдә, ислам динен кабул итәләр, үзләренең фитри иманнарын торгызалар.

Ислам дине кешене дөрес юлны адашудан, хаклыкны - ялганнан, изгелекне - яманлыктан аерырга өйрәтә һәм заман афәтләреннән имин булып, ике дөнья бәхетенә ирешергә ярдәм итә.